УДК 811.512.145

***И.Ф. Миргалимов***

# ТАТАР ДӨНЬЯ КАРТИНАСЫНДА ПРОСТРАНСТВОНЫ ГОРИЗОНТАЛЬ ЯССЫЛЫКТА КҮЗАЛЛАУ МОДЕЛЬЛӘРЕ

Каждый народ имеет свой метод познания пространства и комплекса представлений о его устройстве и космогонии. Многие народы приходят к пониманию данной категории в связи с первобытными представлениями о природных явлениях. В статье анализируются представления пространства у татар в горизонтальном устройстве мироздания.

**Ключевые слова:** горизонтальная плоскость, татарская языковая картина мира, концепт, пространство, модель мира.

Табигый ки, һәр мәдәниятнең үзенә генә хас кыйммәтләр системасы була. Алар арасында гореф-гадәтләр, традицияләр, йолалар, кешенең үз-үзен тоту рәвеше стереотиплары, дөньяны күзаллау белән бәйләнгән кыйммәтләр аеруча мөһим.

«Дөнья моделе», «дөнья картинасы», «дөнья тел сурәте», «концепт» һ.б. терминнар рус тел белемендә XX гасырның 60 нчы елларында ук, ә татар тел белемендә XX гасырның 80–90 нчы елларында гына яктыртыла башлый. Дөнья картинасы – кеше һәм тел, кеше һәм әйләнә-тирә мөнәсәбәтенең чагылышы, Г.А. Брутян билгеләвенчә, берничә буын эшчәнлеге нәтиҗәсе булып тора. Тел ярдәмендә традицияләр, еллар буе тупланган тәҗрибә киләчәк буынга тапшырыла [Брутян, с. 42].

Дөнья моделен иҗат итүнең үзенчәлекле милли ысуллары бар. Халык дөньяны нинди күз белән күрсә, аның аңында шундый дөнья төзелеше формалаша. Бу – әлеге халыкның яшәешне ни рәвешле итеп күрүен аңлатуы һәм ул дөньяның милли образын тәшкил итүе [Сибгаева, б. 123].

Соңгы вакытта тюркологиядә дөньяны тел чаралары ярдәмендә сурәтләү мәсьәләләрен өйрәнүгә игътибар арта башлады. 2006 елда Ә.Р. Тенишев редакциясендә төрки халыкларның дөнья картинасы модельләренә багышланган хезмәт басылып чыкты. Бу хезмәттә авторлар, төрки халыкларның дөнья моделенә вертикаль һәм горизонталь яссылыклар хас, дип язалар [СИГТЯ, с. 326].

Җиһан без яшәгән Җир өсте дөньясы белән генә чикләнми: анда башка – икенче, хәтта өченче дөньялар да бар икән. Шулай булгач, аларда гомер итүче затлар да төрле-төрле булырга тиеш. Җирдә булмаган һәм һич тә була алмаган күренешләрнең, затларның барысы да Җир асты яки Су асты патшалыкларында була. Тулаем алганда, бу патшалыклар, бу дөньялар билгеле бер

дәрәҗәдә Җир өсте патшалыгының киресен гәүдәләндерәләр [Урманче, б. 20–21].

Төркиләргә хас булган кебек үк, татарлар өчен дә дөнья вертикаль һәм горизонталь яссылыкта күзаллана. Вертикаль моделе өч өлештән торса (күк – җир – җир асты), горизонталь дөнья исә дүртпочмаклы яссылыктан гыйбарәт (дөнья яклары – аның дүрт почмагы, уң – сул, ал – арт).

Татар дөнья картинасында пространствоның *горизонталь яссылыгы* ал – арт (ян – як), киң – тар модельләрендә чагылыш таба.

1) *ал – арт, ян – як* моделе.

*Ал – арт, ян – як* пространствоны горизонталь яссылыкта характерлый торган берәмлекләр булып исәпләнәләр. Иң элек бу сүзләргә аңлатма биреп китик.

Аңлатмалы сүзлектә пространство белән бәйле *ал* сүзенә түбәндәге аңлатма бирелә: күз караган як; *кирес*е арт [ТТАС, б. 32]; *арт* сүзенә: күз караган якка капма-каршы як [ТТАС, б. 48]; *ян*: нәрсәнең дә булса уң яки сул ягы // янга урнашкан, ян-якка урнашкан, яндагы [ТТАС, б. 732].

Р. Харис икътисад, сәүдә якларыннан үсеш һәм яңарыш кичергән, алдынгы цивилизацияле дәүләтләрне *алга* киткән дәүләтләр дип атый:

*Үз-үземә туа үтенеч:*
***алга кара** – тормыш **алда** гына,*
***ян-як** – гыйбрәт, **артта** –*
*үкенеч...*
(«Тормыш алда гына»)

Р. Харис бу шигырендә пространствоны горизонталь яссылыкта характерлый торган сүзләр ярдәмендә тормышка бәя бирергә тырыша. Тормышның үткәне күңелдә үкенеч калдыра, кешегә тәҗрибә, гыйбрәт өсти. *Алда* кешене киләчәге көтә. Үткәнне автор *арт,* киләчәкне *ал* дип атый. Ул *алга кара* гомумтел фразеологик берәмлеге аша киләчәк белән яшәү мәгънәсен җиткерә:

*Без дигәнчә бармый тормыш-сыер:*
***Алга кусаң – артка борыла...***
(«Тормыш-сыер»)

Әлеге шигырендә авторның тормыш турындагы күзаллавы пространствоны горизонталь яссылыкта характерлый торган *ал – арт* берәмлекләре белән җиткерелә.

Алдагы мисалда шагыйрь лирик геройның хис-кичерешләрен табигать күренеше белән параллель тасвирлый. Ул бу очракта да пространствоны горизонталь яссылыкта характерлый торган *арт* сүзенә мөрәҗәгать итә:

*Кояш бата зәңгәр **тау артына...***
*Яшел алан моңга күмелә...*
*Сагынудан шашам бугай инде –*
*Син кайларда хәзер?*
(«Кояш бата зәңгәр тау артына...»)

Зөлфәт *алда* лексик берәмлеген лирик геройның киләчәк, алдагы тормышка карата булган якты өметләрен тасвирлаганда куллана:

Ә безнең бит – яшиселәр ***алда***
Еллар ямьле, юллар күңелле!
Еласак та, көлсәк-елмайсак та,
Ашыктырмыйк әле күңелне...
(«Таң җилендә кипсен керфекләр...»)

Нәтиҗә ясап әйтсәк, *ал – арт, ян – як* модельләре пространствоны горизонталь яссылыкта сурәтләгәндә, төп вазифаларыннан тыш, поэзиядә фәлсәфи төшенчәләрне, күзаллауларны җиткерү өчен ачкыч сүз буларак та кулланылалар.

2) *киң – тар* моделе.

*Киң* 1) буйга, озынлыкка сузылган яссылыклар, өслекләр, мәйданнар турында. Иңе чагыштырмача зур; 2) зур араларга җәелгән, җәенке; 3) *сөйл.* иркен; күләмле; 4) зур; 5) *күч.* чикләнмәгән, мул; тулы, юмарт [ТТАС, б. 261].

*Тар* – 1. *сф.* 1) иңе чагыштырмача зур булмаган, киң түгел; 2) сыю, сыйдыру, үтәли узу кыен булган (*һәртөрле ачыклыклар, аралыклар тур.*); 3) таманыннан яисә гадәттәгедән ныграк тәнгә ятып тора торган (*кием-салым тур.*); 4) кысан, уңайсыз; 5) *күч.* колачсыз, масштабсыз, кимчелекле; 6) *күч.* эгоистик, көнчелекле; хөсетле, хөсетчән; 2. *рәв. мәгъ. күч.* берьяклы рәвештә, бер яктан гына; 3. *хәб. сүз.* аз, кысан (*мөмкинлекләр, сәмән һ. б. тур.*); аз, ашыгыч (*вакыт тур.*) [ТТАС, б. 516].

Г. Зәйнашева «Менәргә иде Урал тауларына» җырында пространствоны киңлектә сурәтли. Лирик герой илен *киң* итеп күрә. Аның Урал тауларына менеп, *киң илен* нурга күмеп таң атканын күрәсе килә:

*Каршыларга иде* ***киң илемне,***
*Нурга күмеп таңнар атканын*
(«Менәргә иде Урал тауларына»).

Авторның «Сөембикә» исемле шигъри монологы тарихны яктырта. Шагыйрь дошманнарның Казан ханлыгын яулап алып, олуг һәм *киң* булган илне җимереп, яндырып, халкын кол итүләре турында яза. Ул Сөембикә исеменнән сөйли, әсәр структур яктан ханбикә монологына корылган:

*Илем-йортым олуг иде,*
*Олуг иде,* ***киң*** *иде*
(«Сөембикә»).

Зөлфәт «Язмышлар ярында» шигырендә төп мәгънәне яшереп бирә. Мөмкинчелек, яшәү шартлары туры килмәү, күңел тарлыгы мәгънәләрен *урамым тар булган* индивидуаль автор фразеологизмы белән җиткерә:

Артык зур булгандыр бәхетең,
*Я минем* ***урамым тар булган***
(Зөлфәт).

Шул рәвешчә, татар шигъриятендә шагыйрьләр пространствоны киңлектә, киң итеп сурәтлиләр. Шуның белән бергә *киң – тар* сүзләре индивидуаль автор фразеологизмнары составында да мул кулланыла.

Нәтиҗә ясап әйтсәк, пространство яки урын-ара ул, иң беренче чиратта, безне чолгап алган дөнья, галәм, яшәеш, барлык, тереклек. Ягъни ул – киңлек; җир, урын; аралык, бушлык; мәйдан; материя яшәешенең төп объектив формаларның берсе; ачык урын, ачыклык; фәлсәфи төшенчә; *ал, арт, өс, ян* һ.б.

**Әдәбият**

*Брутян Г.А.* Язык и картина мира // Философские науки. 1973. № 1. С. 108–119.

*Сибгаева Ф.Р.* Пространство в картине мира поэтической фразеологии татарского языка // Ученые записки Казанского университета. Серия: Гуманитарные науки. 2008. Т. 150. № 8. С. 123–127.

СИГТЯ – Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Лексика / под ред. Э.Р. Тенишева. М.: Наука, 2001. 986 с.

ТТАС – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты. 2005. 849 б.

*Урманче Ф.И.* Татар мифологиясе: энциклопедик сүзлек: өч томда. 2 т. Казан: Мәгариф, 2009. 343 б.

***Миргалимов Илдар Флүс улы,***
*Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе урынбасары*
*E-mail: ildarfm.kazan@gmail.com*